| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16. 12. 2019 г.Зеленодольск № 451

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр бирү кагыйдәләре турында

«Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтеваның мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге Карарның нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына йөкләргә.

4.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**башлыгы урынбасары** **Э.Р.Кадникова**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ * ИНН 1648017831 КПП 164801001

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2019 елның16 декабрендәге
карары белән расланды

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына (алга таба - субвенцияләр, җирлекләр) субвенцияләр бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы булып, граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган субвенцияләр тора.

4. Әлеге кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының баш бүлүчесе - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет).

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына тиешле финанс елына һәм план чорына субвенцияләр бүлеп бирү Зеленодольск муниципаль районы Советының муниципаль район бюджеты карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм Башкарма комитетына билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Граждан хәле актлары язмаларын төзү һәм башка юридик әһәмиятле гамәлләрне башкару өлешендә субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыруга бирелә:

Хезмәт хакы һәм хезмәт өчен өстәмә түләүләр;
командировка чыгымнары;
элемтә хезмәтләре күрсәтү;
транспорт хезмәтләре күрсәтү;
коммуналь хезмәтләр күрсәтү;
мөлкәттән файдалану хезмәтләре күрсәтү;
эш, мөлкәт эчтәлеге буенча хезмәт күрсәтүләр;
башка эшләр, хезмәтләр күрсәтү;
төп чаралар сатып алу;
матди запаслар сатып алу;
салымнар, җыемнар һәм башка түләүләрне түләү;
башка чыгымнар.

9. Субвенцияләрне тоту Федераль казначылык Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының җирлекләр бюджетын үтәүгә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган (алга таба - казначылык) шәхси счетлары аша гамәлгә ашырыла.

10. Башкарма комитет финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен, чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә, Казначылыкта субвенцияләр акчалары исәбеннән җирлекләр бюджетына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза тапшыра.

11. Квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның, 5 числосыннан да соңга калмыйча, җирлекләрнең җирле үзидарә органнары финанс белән тәэмин итү чыганагы субвенция булган граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле җирлекләр бюджетларының чыгымнары турында хисапны, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы белән килештереп, Россия Федерация Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Башкарма комитетына тапшыра.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекнең Башкарма комитетына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты керемәнә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр биргән елдан соң килүче елның 1 гыйнварына билгеләнмәгән субвенцияләрнең калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлардан тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын, законнар нигезендә, Башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органы контрольдә тота.